**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ПЕСЧАНО-КОВАЛИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
422625 с. Песчаные Ковали,
ул. Октябрьская,д.9а
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАИШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ КОМЛЫ КОВАЛ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
422625 с. Комлы Ковал авылы,
ул. Октябрьск урамы, 9 а нчы йорт,
тел: 8 84378 4-56-47
тел: (факс) 8 84378 4-56-41
E-mail: Pkov.La@tatar.ru

**2026 елның 27 феврале** **10 номер**

# КАРАР

## Җир участогыннан шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләү турында

«Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы-Ковал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясен тотрыклы үстерү, әйләнә-тирә мохитне саклау өчен шартлар тудыру, территорияләрне планлаштыру өчен шартлар булдыру, физик һәм юридик затларның хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен тәэмин итү, инвестицияләр җәлеп итү өчен шартлар тудыру максатыннан, Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 46 нчы статьясындагы 4 нче пунктын, «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ санлы Федераль законны, «Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Комлы-Ковал авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә,

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Валентина Ивановна Гильфановадан кергән, 16:24:090108:552 кадастр номерлы җир участогыннан «Блоклаштырылган торак төзелеше» дигән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлаулар билгеләргә.

2. Ачык тыңлауларны уздыру чорын – кызыксынучы затларны аларны уздыру турында хәбәр иткән мизгелдән башлап ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы нәтиҗә басылып чыккан көнгә кадәр дип билгеләргә.

3. Эшче комиссиягә Валентина Ивановна Гильфановадан кергән, 16:24:090108:552 кадастр номерлы җир участогыннан «Блоклаштырылган торак төзелеше» дигән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төренә рөхсәт бирү мәсьәләсе буенча ачык тыңлауларны оештыру һәм уздыру эшенә әзерлек алып барырга:

3.1. Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 5.1 статьясында күздә тотылган ачык тыңлаулар башлану турындагы хәбәрнамәне әзерләргә;
3.2. Ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турындагы нәтиҗә басылып чыккан көннән башлап ике эш көне эчендә, карар кабул итү өчен кирәкле документлар пакетын теркәп, Татарстан Республикасында җирлекләрдән файдалану һәм төзелеш кагыйдәләре проектын әзерләү буенча Комиссиягә мәгълүмат җиткерергә.

4. Әлеге Карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (веб-адресы: http://pravo.tatarstan.ru) һәм Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында (веб-адресы: https://laishevo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

5. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан (халыкка җиткерелгән) көненнән нәтиҗәле көченә керә.

6. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны үз өстемдә калдырам.

**Җитәкче** **А.Ф. Миндубаев**